ГЛАВА КАНАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.4, д. Канаш,
422584

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КАНАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Үзәк ур., 4 нче йорт, Канаш авылы,
422584

Тел.: (84379) 36-7-45, факс: (84379) 36-7-45.

5.11.2019 №1

**Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлегенең Йолдыз авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**
**КАРАР**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 елның 6 ноябрендә булып узган «2020 елда Канаш авыл җирлегенең Йолдыз авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә җибәрү белән килешәсезме» соравы буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде:

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлегенең Йолдыз авылында юлларга вак таш җәю.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 12 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар санынннан 11 кеше тавыш бирүдә катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 4 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 7 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлегендә узган халык җыенын үткән дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен-чын дип танырга.
2. "2020 елда Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлегендә Йолдыз авылында яшәү урыны буенча Югары Ослан муниципаль районының Йолдыз авылында теркәлгән, авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән билгеләнгән ташламалы категория гражданнардан тыш, һәр балигъ булмаган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме? – Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлегенең Йолдыз авылында юлларга вак таш җәю.

3. Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлегенең Йолдыз авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Канаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлеге Башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актларын теркәүгә җибәрү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Н.Н. Вальков